ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.10.2022 ел Баулы шәһәре №204

Яшь гаиләләргә торак сатып алуга
бирелә торган социаль түләүләр
күләмен исәпләү өчен 2022 елның
дүртенче кварталына Баулы муниципаль
районы буенча гомуми торак мәйданының
бер квадрат метры бәясенең нормативын
билгеләү турында

«Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2022 елның 20 сентябрендәге 773/пр номерлы «Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынының гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» боерыгы нигезендә 2022 елның 1 кварталына «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлыкның Эксперт-консультация советының 2022 елның IV кварталына торак урыннарның бер квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча тикшеренүләре нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 2022 елның дүртенче кварталына Баулы муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясенең нормативын билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазифаларын башкаруы И.И. Хөснуллина